ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2019 Казан шәһәре № 10-40/кс

«Пивоварня Москва-Эфес» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 №10-168/кс карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2020-2023 елларга эчә торган суга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Пивоварня Москва-Эфес» акционерлык җәмгыяте өчен 2019-2023 елларга эчә торган суга тарифлар билгеләү турында» 14.12.2018 №10-168/кс карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышында «Пивоварня-Москва-Эфес» акционерлык җәмгыятенең Казан шәһәрендәге филиалының» сүзләрен «АБ Инбев Эфес» акционерлык җәмгыятенең Казан шәһәрендәге филиалы» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Пивоварня-Москва-Эфес» акционерлык җәмгыятенең Казан шәһәрендәге филиалының» сүзләрен «АБ Инбев Эфес» акционерлык җәмгыятенең Казан шәһәрендәге филиалы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Пивоварня-Москва-Эфес» акционерлык җәмгыятенең Казан шәһәрендәге филиалының» сүзләрен «АБ Инбев Эфес» акционерлык җәмгыятенең Казан шәһәрендәге филиалы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Пивоварня-Москва-Эфес» акционерлык җәмгыятенең Казан шәһәрендәге филиалының» сүзләрен «АБ Инбев Эфес» акционерлык җәмгыятенең Казан шәһәрендәге филиалы» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 № 10-168/кс карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.11.2019 № 10-40/кс карары редакциясендә)

## Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «АБ Инбев Эфес» акционерлык җәмгыятенең Казан шәһәрендәге филиалы өчен эчә торган суга 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «АБ Инбев Эфес» акционерлык җәмгыятенең Казан шәһәрендәге филиалы (тарифлар өстәлгән хак бәясен исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 8,12 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 10,00 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 8,51 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 8,51 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 8,51 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 8,93 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 8,93 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 8,98 |

| №<br>п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф<br>(бер ставкалы),<br>сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2023 башлап<br>30.06.2023 кадәр | 8,98 |
| | | 01.07.2023 башлап<br>31.12.2023 кадәр | 9,41 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 № 10-168/кс карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.11.2019 № 10-40/кс карары редакциясендә)

«АБ Инбев Эфес» акционерлык җәмгыятенең Казан шәһәрендәге филиалы өчен эчәргә яраклы суга 2019-2023 елларга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, Тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «АБ Инбев Эфес» акционерлык җәмгыятенең Казан шәһәрендәге филиалы | | | | | | |
| 1.1 | Эчә торган су | 2019 | 6246,07 | 1 | - | - | 0,41 |
| | | 2020 | 6369,12 | 1 | - | - | 0,41 |
| | | 2021 | 6538,73 | 1 | - | - | 0,41 |
| | | 2022 | 6732,28 | 1 | - | - | 0,41 |

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, Тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| | | 2023 | 6931,55 | 1 | - | - | 0,41 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге